КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № б-3043

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 11 декабрь, б-1986 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 13 август, 652 нче карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 24 июль, б-1338 нче; 2015 ел, 10 апрель, б-643 нче; 2017 ел, 19 август, б-2073 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, б-2247 нче; 2020 ел, 11 февраль, б-260 нчы; 2020 ел, 24 август, б-1632 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең чиктәш субъектлары арасында бәхәсле чикләр мәсьәләләрен хәл итү буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан А.В.Самойловны, Т.Ф.Хөснетдиновны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары Максим Анатольевич Рогожкинны;

«Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Айрат Нәгыйм улы Усмановны (килешү буенча);

Айрат Миңнемарсил улы Шиһаповның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары»;

Руслан Викторович Комаровның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин